КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 август г.Казань № 873

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратуга әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 414 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 04 сентябрь, 809 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратуга әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Агентлык сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыра.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасын, ул сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

субсидия бирү нәтиҗәләре;

Агентлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итәлә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган тәкъдимнәр (гаризалар) һәм тәкъдимнәр (гаризалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне бирү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару (шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (заявкаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карау кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлау нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

13 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Агентлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүләргә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

20 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Агентлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечәнә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

24 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада

мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 539 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 683 нче, 2021 ел, 23 сентябрь, 904 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Агентлык сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыра.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасын, ул сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

субсидия бирү нәтиҗәләре;

Агентлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган тәкъдимнәр (гаризалар) һәм тәкъдимнәр (гаризалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне бирү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару (шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару

өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (заявкаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карау кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлау нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

14 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Агентлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүләргә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

21 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Агентлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

25 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 05 август, 679 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Агентлык сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыра.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасын, ул сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

субсидия бирү нәтиҗәләре;

Агентлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган тәкъдимнәр (гаризалар) һәм тәкъдимнәр (гаризалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне бирү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару (шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (заявкаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карау кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлау нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

13 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Агентлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүләргә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

21 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Агентлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

25 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда татар теленә тәрҗемә ителгән уку-укыту-методик комплектларны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккреди-тациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертүгә әзерләү чыгымнарын каплау өчен дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителә торган уку ярдәмлекләрен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар исемлегенә кертелгән оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 сентябрь, 906 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 елда татар теленә тәрҗемә ителгән уку-укыту-методик комплектларны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккреди-тациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертүгә әзерләү чыгымнарын каплау өчен дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителә торган уку ярдәмлекләрен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар исемлегенә кертелгән оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган бюджет ассигнованиеләре күләме  һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба - Агентлык) законнарда билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Агентлык сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыра.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) бирә башлау яисә кабул итү тәмамлану датасын, ул сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

субсидия бирү нәтиҗәләре;

Агентлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган тәкъдимнәр (гаризалар) һәм тәкъдимнәр (гаризалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне бирү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару (шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (заявкаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карау кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлау нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

13 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Агентлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүләргә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

18 пунктның җиденче абзацында «2021 ел» сүзләрен «субсидия бирү елы» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктта «2021 ел» сүзләрен «субсидия бирү елы» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Субсидия алучы субсидия бирү елыннан соң килүче елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең үрнәк формасына кушымта итеп бирелә торган форма буенча Агентлыкка субсидия бирүнең нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап тапшыра.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Агентлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

25 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. Әлеге карар, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кертә торган әлеге карарның 1 пунктындагы егерме өченче абзацыннан, 2 пунктындагы егерме өченче абзацыннан, 3 пунктындагы егерме өченче абзацыннан, 4 пунктындагы утыз икенче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. 2023 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлне туктатырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 414 нче карары белән расланган Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 539 нчы карары белән расланган Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган

мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибен « 2021 ел, 05 август, 679 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда татар теленә тәрҗемә ителгән уку-укыту-методик комплектларны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертүгә әзерләү чыгымнарын каплау өчен дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителә торган уку ярдәмлекләрен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар исемлегенә кертелгән оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 сентябрь, 906 нчы карары белән расланган 2021 елда татар теленә тәрҗемә ителгән уку-укыту-методик комплектларны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертүгә әзерләү чыгымнарын каплау өчен дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителә торган уку ярдәмлекләрен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар исемлегенә кертелгән оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин